ГЛАВА КУРАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КУРАЛОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

07.10.2020 | с. Куралово | 02

Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Рус Борнашы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020нче елның 20нче октябрендә 13 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Рус Борнашы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020нче елның 20нче октябрендә 15 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Рус Борнашы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 этап: Рус Борнашы авылының Цветочная урамында яшәүчеләр

2 этап: Рус Борнашы авылының Совет урамы, Дальняя урамы, Заречная урамнарында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Рус Борнашы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә ризамы:

- Рус Борнашы авылында эшләп килүче юлга вак таш салу

«ӘЙЕ» «ЮК»

5. Халык җыеннары үткәрергә:

1 этап: Рус Борнашы авылының Зур урамы буенча 4-нче номерлы йорт янында

2 этап: Рус Борнашы авылының Заречная урамы буенча 1-нче номерлы йорт янында

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге башлыгы В. А. Квашнева